**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы № 26 01 июнь, 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты хакында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр кертү белән бәйле

Сарлы авыл җирлеге Советы карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Советы карары проектын кабул итәргә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны, 2021 елның 05 июненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http:// aznakyevo.tatarstan.ru, Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. 2021 елның 02 июлендә 17.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк урам, 68А йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Сарлы авылы, Үзәк урам, 68А йорт.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем төзергә:

- М.Р.Шәрипов – Сарлы авыл җирлеге Башлыгы;
- Җ.Г.Гыймаев – Сарлы авыл җирлеге депутаты;
- Д.Н.Миннеханов – Сарлы авыл җирлеге депутаты.

6. Ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркемгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча  ачык тыңлаулар үткәрүне, гражданнарны кабул итү, исәпкә алуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссия халык алдында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә тиеш.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис                                                        М.Р.Шәрипов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге Советы
карарына 1 нче кушымта
«01» июнь 2021 № 26

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 гыйнварындагы 37 номерлы карары белән расланган карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Сарлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына (24.09.2012 №51, 05.08.2013 №72, 22.10.2014 №68-30, 30.09.2015 №9-2, 15.11.2016 №39-22, 17.04.2018 №90-45, 03.09.2018 №105-54, 05.11.2019 №145-72, 17.11.2020 №11 карарлар редакциясендә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Сарлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 17 пунктча өстәргә:
«17) алкоголь, наркотик яки башка токсик исереклек хәлендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

1.2. 47 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:
« - алкогольле, наркотик яки башка токсик исереклек хәлендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http:// aznakyevo.tatarstan.ru., Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.